**ГЛАВА АЗЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Ул. Советская, д.22,
с. Азеево,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АКЪЯР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

Совет урамы, 22 нче йорт
Акъяр авылы,423190

тел.: (8- 84348) 3-71-31, факс: (8-84348) 3-71-61, Azeev.Nsm@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2021 елның 21 октябре №1

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 22, 81 статьялары нигезендә , Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлеге башлыгы

Карар:

1. Машина – трактор паркында 2021 елның 3 ноябрендә 7 . 00 сәгатькә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. Нариманов урамы буенча 10 нчы йорт янында 2021 елның 3 ноябрендә 9.00 сәгатькә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлегенең үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. Акъяр Мәдәният йортында (Совет урамы, 20 нче йорт) Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлегенең үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының өченче этабын 2021 елның 3 ноябрендә 10.30 сәгатькә билгеләргә.
4. Гражданнар җыенын уздыру өчен Акъяр авылында яшәүчеләрнең исемлеген аерым бүлүне сайлау тәртибе территориаль билге буенча башкарылырга тиеш.
5. Гражданнар Җыенының этапларын оештыру һәм үткәрү Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.
6. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез,Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлегендә яшәүче урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 2022 нче елга, 500 сум күләмендә үзара салым җыю белән килешәсезме?

Үзара салым түләүдән көндезге бүлектә укучы студентлар, 1 нче группа инвалидлар азат ителә. Үзара салым түләүдән җыелган акчаларны түбәндәге хезмәтләр өчен кулланылачак:

- авыл эчендәге юлларны төзекләндерү (юлларны ташландыру, сатып алу, китерү, таш түшәү, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- җәйге вакытта территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, эшләр һәм килешү буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
-- объектларга һәм су белән тәэмин итү системасына хезмәт күрсәтү һәм агымдагы ремонт (материал сатып алу, агымдагы ремонт, өзеклекләрне бетерү, килешү буенча эш өчен түләү, шул исәптән сусактыру операторына да);
-- юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча түләү;
- зиратны төзекләндерү (коры агачларны кисү,зират тирәсен буяу өчен буяулар сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү).

“ӘЙЕ” “ЮК”.

7. Әлеге карар Интернет «мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru, Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга (игълан итәргә), гражданннар Җыенына кадәр 10 көн алдан мәгълүмат тактасында эленеп торырга тиеш.

8. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Акъяр авыл җирлеге башлыгы Д. С. Гайнуллин